СОВЕТ ТАВЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Нагорная, д.70, с. Тавели,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422160

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАУИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Тау өсте урамы, 70 йорт, Тауиле авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы, 422160

Тел. (факс): (85563) 2-67-25 e-mail: Tavel.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар

“24” марта 2022 г. | № 1-15

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 29 декабрендәге №468-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Мамадыш районы прокуратурасының 2022 елның 17 мартындагы №02-08-02-2022 протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегенең 2014 елның 20 декабрендәге 1-39 номерлы Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә (05.06.2018 ел, №6-33; 29.04.2019 ел, №3-42; 19.02.2020 ел, №5-51; 17.05.2021 ел, №1-8 карарларындагы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 35 статьяда: «Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналар» бүлегенең «Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында билгеләнгән территориаль зоналар төрләре» бүлеге 35 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Яңа төзелә торган җир кишәрлекләренең чик күләме:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1000 кв. м., шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару яки шәхси торак төзелеше өчен рөхсәт ителгән файдалану төре белән, кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү юлы белән мәйданы 1000 кв метрдан да кимрәк җир кишәрлекләре барлыкка килгән очраклардан тыш.

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән җир кишәрлекләренең максималь күләме-5000кв. м.»

Дәүләт яисә муниципаль милектә булган җирләрдән гражданнарга арендага яки милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең чик (максималь һәм

минималь) күләмнәрен билгеләргә:

а) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен:

- торак пункт чикләрендә (йорт яны җир участогы) - 0,1 гектардан алып 0,5 га кадәр.,

- торак пункт чиге (кыр җир участогы) - 0,1 га дан 1,0 га кадәр;

б) шәхси торак төзелеше өчен 0,1 гектардан алып 0,5 га кадәр.»;

1.2. 27 статьяның 5 пунктындагы 6 пунктчасына ", блоклап төзелгән барлык
йортларның да хокук ияләренең бер рәттәге ризалыгы турында"сүзләрен өстәргә;

2. Әлеге карарның 1.1. пунктында каралган җир кишәрлекләренең иң чик (максималь һәм минималь) күләме гражданнарга әлеге карар үз көченә рәсми кергәннән соң бирелә торган җир кишәрлекләренә (Яңа бүлеп бирелә торган җир кишәрлекләренә) кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1.1. пунктында каралган җир кишәрлекләренең иң чик (максималь һәм минималь) күләме гражданнарга әлеге карар кабул ителгәнче арендага бирелгән һәм гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә алар сатып алган җир кишәрлекләренә кагылмый дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Т (pravo.tatarstan.ru) игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге башлыгы Ивановка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Тауиле авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе / В.И.Иванов/

СОВЕТ ТАВЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1626001348